СОВЕТ
РОМОДАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
РОМОДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

21.05. 2020 с. Ромодан № 112

**«Җир салымы турында» 2018 елның 16 ноябрендәге 71 номерлы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән Россия Федерациясе Салым кодексының 395 маддәсе нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Ромодан авыл җирлеге Советы карар кылды:**

1. «Җир салымы турында» 2018 елның 16 ноябрендәге 71 номерлы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) дини оешмалар - дини һәм хәйрия билгеләнешендәге биналар, төзелешләр һәм корылмалар урнашкан җир кишәрлекләренә карата».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан, әмма Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет челтәрендә рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында җирле үзидарә сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Ромодан авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **И.А. Чекалина**

СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ